**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ**
**исполкома Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитетының**
**МӘГАРИФ ИДАРӘСЕ**

423330, РТ, г.Азнакаево,ул.Ленина, 14.
тел. 7-04-08, 7-01-03 azn-uo@rambler.ru,

423330, ТР, Азнакай шәһәре,Ленин ур,14.
тел. 7-04-08, 7-01-03 azn-uo@rambler.ru

**№1019** **10 нчы март 2015 нче ел**

Азнакай шәһәре 4 нче лицее татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рафикова Эльвира Алмарис кызының педагогик эшчәнлегенә бәяләмә

Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү бюджет учреждениесе "Азнакай шәһәре 4 нче лицее"нең I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рафикова Эльвира Алмарис кызы 16 ел укучыларга татар теле һәм әдәбияты фәнен укыта. Ул, "Коммуникатив технологияләр кулланып, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү" дигән методик тема, белем бирүдә югары сыйфатка ирешүдә инновацион технологияләр, сингапур укыту ысулларын, проблемалы укыту, проект, компьютер технологияләрен кулланып, укучыларга ныклы белем һәм тәрбия бирә.

Эльвира Алмарис кызы - балаларны яратып, аңлап, чын йөрәктән эшләүче укытучы. Һөнәри эшчәнлегенең асылы: "Өйрән! Иҗади эшлә! Җиңүгә омтыл!" дигән девиз. Шулай ук тәрбияле, белемле, бар яктан булган шәхес, ягъни көндәшлеккә сәләтле, тормышка яраклы укучы тәрбияләү.

Аның дәресләре заманча, эчтәлекле һәм укучыларның тел культурасын үстерүгә, белемле, тәрбияле булуга, туган телне, аның тарихын, мәдәниятен яратуга юнәлтелгән. Тырыш укытучы дәресләрдә, һәр баланың психологик һәм яшь үзенчәлекләрен аңлап, үзара аңлашу атмосферасы тудыра, иҗади эшчәнлекләрен үстерә, Сингапур укыту алымнарын кулланып, укучыларның креатив фикерләү сәләтләрен үстерә, дәресләрдә үзара хезмәттәшлек тудыра.

Мөгаллимә укучыларга ышанычын күрсәтә, мөстәкыйль эшләүләренә юл куя. Аның укучыларының язмалары район һәм республика күләмендә чыгарыла торган "Маяк", "Көмеш кыңгырау" газеталарында, "Ялкын"

журналында басыла.

Эльвира Алмарис кызы укытуда да, тәрбия эшендә дә югары нәтиҗәләргә ирешә. Район күләмендә предмет буенча уздырылган олимпиадаларда, республика конкурс-бәйгеләрендә катнашып, аның укучылары призлы урыннарны яулыйлар.

Үзбелем белән уртаклашып, Рафикова Э.А. Азнакай шәһәре №1, №5 нче мәктәпләрендә уздырылган республика семинарларында катнаша, шәһәр һәм район семинарларында ачык дәресләр һәм сәхнәләштерелгән әсәрләр күрсәтә, методик темасы буенча чыгышлар ясый, республика буенча уздырылган "Ел укытучысы", Бөтенроссия "Мастер-класс" бәйгесенең муниципаль этабында катнашып, җиңүләргә ирешә.

Максатчан, яңалыкка омтылучан, эзләнүчән мөгаллимәгә 2013 нче елда "Сәхнә көзгесе" республика күләм милли балалар театр фестивалендә катнашып, яшь буынга татар милли театр сәнгатен өйрәтүдәге уңышлары өчен ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының рәхмәт хаты тапшырыла. 2014 нче елда Кәрим Тинчуринның тууына 127 ел тулу уңаеннан уздырылган "Ул кабызган утлар балкышы" бәйгесендә актив катнашканы өчен сертификат бирелә. 2015 нче елда "Балалар шагыйре, фронтовик, мөгаллим Әнәс Кари мирасы һәм хәзерге заман (тууына 95 ел)" төбәкара фәнни-гамәли укытучылар конференциясендә катнашып, сертификатка ия була. "Татнефть" үткәргән (субпортал "”Татнефть”ка 60 ел") иҗади конкурсында "Синең геройларың, ”Татнефть”! - 1 нче урын, "Компаниянең тарихы турында иң яхшы белүче" конкурсында дипломга лаек булды.

Рафикова Э.А. киләчәккә зур планнар белән, заман таләпләренә туры килерлек итеп, эшләвен дәвам итә.

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе җитәкчесе:** **Э.Й. Зарипова**

Муниципальное казённое учреждение "Управление образования исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района" ИНН 1643011811 КПП 164301001 ОГРН 1111689000104